СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2021 г. Заинск № 193

**«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисенең, Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 279 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2014 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 17 декабрендәге 1087 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисенең, Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 279 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына (Зәй муниципаль районы Советының 2018 елның 22 октябрендәге

341 номерлы, 2020 елның 27 августындагы 553 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемдә «рәисе» сүзеннән соң «, рәис урынбасарлары, аудиторлар» сүзләрен өстәргә;

1.2. 1 пунктта «рәисе» сүзеннән соң «, рәис урынбасарлары, аудиторлар» сүзләрен өстәргә;

2. Зәй муниципаль районы Советының 2018 елның 13 апрелендәге 279 номерлы карары белән расланган Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисенең, Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Исемдә «рәисе» сүзеннән соң «, рәис урынбасарлары, аудиторлар» сүзләрен өстәргә;

2.2. 1 бүлектә 1.2 пунктта «рәисе» сүзеннән соң «, рәис урынбасарлары, аудиторлар» сүзләрен өстәргә;

2.3. 2 бүлектә исемдә «рәисе» сүзеннән соң «, рәис урынбасарлары, аудиторлар» сүзләрен өстәргә;

2.4. 2 бүлекнең 2.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәр ул элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеменә керә торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә, класс чины өчен аның оклад күләме ул биләгән вазыйфа кергән вазыйфалар төркеме өчен беренче класслы чин бирелгәнче, вазыйфаи окладка карата процент ставкасыннан чыгып, 3 процентка тигез итеп исәпләнә.

Муниципаль хезмәткәр ул элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаларының түбәнрәк төркеменә керә торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән очракта, һәм моңа кадәр биләгән вазыйфа буенча аңа бирелгән класс чины, класс чины өчен оклад күләмен исәпләү вазыйфаи окладка процент ставкасыннан чыгып, 7 процентка тигез итеп исәпләнә.

2.5. 2 бүлектә 2.16 пунктта «рәисе» сүзеннән соң «, рәис урынбасарлары, аудиторлар» сүзләрен өстәргә;

2.6. 2 бүлекнең 2.24 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацларны өстәргә:

«Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасарларына, айлык акчалата түләүдән һәм ел саен бирелә торган түләүле отпускка чыкканда бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, өстәмә рәвештә эш нәтиҗәләре буенча ай саен акчалата бүләк, премияләр дә түләнергә мөмкин. Шул ук вакытта аларның айлык акчалата түләүләренең җыелма күләме контроль-хисап палатасы рәисенең айлык акчалата түләүләренең 0,8 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.

Контроль-хисап палатасы аудиторларына, айлык акчалата түләүдән һәм ел саен бирелә торган түләүле отпускка чыкканда бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, өстәмә рәвештә эш нәтиҗәләре буенча ай саен акчалата бүләк, премияләр дә түләнергә мөмкин. Шул ук вакытта аларның айлык акчалата

түләүләренең җыелма күләме контроль-хисап палатасы рәисенең айлык акчалата түләүләренең 0,6 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.»;

2.7. 2 бүлекнең 2.25 пунктында «рәисе» сүзеннән соң «, рәис урынбасарлары, аудиторлар» сүзләрен өстәргә;

3. Зәй муниципаль районы Советының 2018 елның 13 апрелендәге 279 номерлы карары белән расланган «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисенең, Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» Нигезләмәгә 1 нче кушымтада түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. Кушымта исемендә «рәисе» сүзеннән соң «, рәис урынбасарлары, аудиторлар» сүзләрен өстәргә;

3.2. 1 юлның «Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе, контроль орган аудиторы» графасында «, контроль орган аудиторы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3. Зәй муниципаль районы Советының 2018 елның 13 апрелендәге 279 номерлы карары белән расланган «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисенең, Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, карар, 2 пунктның 2.4 пунктчасыннан кала, ул 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Зәй муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

6. Карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары П.С. Уразайкинга йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә
гамәлгә ашыручы җирле үзидарә
депутатларының, сайланулы вазыйфаи
затларының, контроль-хисап палатасы
рәисенең, Зәй муниципаль районы
муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте
өчен түләү тәртибе һәм шартлары
турында» Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 4 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 31 966 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 28 767 |
| Депутатлар | 15 492 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 13 166 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 28 767 |
| Контроль-хисап органы рәисе урынбасары | 25 871 |
| Контроль-хисап органы аудиторы | 20 927 |